№74 (1114)
11 ноябрь
2006 ел

Көмеш кыңгырау

1996 елның 1 гыйнварыннан чыга башлады

Рубис ЗАРИПОВ

Балачагым җырлары

Шәһәрдәшебез Рубис Зарипов үз сүзләренә көйләр иҗат итеп бик матур җырлар тудырган.

Сез аларны бәйрәмнәрдә, кичәләрдә җырларсыз.

Балачак яңа җырлар белән бизәлсен!

"Көмеш кыңгырау" китапханәсе

Йомшак кар



Йомшак кар явып үттеме,
Ишек алды җанлана.
Бала-чага йөгреп чыга
Кулына тотып чана.

Кушымта:
Кар яуганда рәхәт тә соң,
Янып-пешеп уйныйсың.
Йөгерәсең, шаярасың,
Уйнап һич тә туймыйсың.



Чана тартып та уйныйлар,
Чаңгыда да шуалар.
Юеш карны тәгәрәтеп
Кар кыз ясап куялар.

Кушымта:
Кар яуганда рәхәт тә соң
Янып-пешеп уйныйсың.
Юешләнеп бетсәң дә,
Уйнап һич тә туймыйсың.

Ак карга кумелгәннәр

Нәфисә Баязитова сүзләре.



Кур әле син агачларны,
Ак бәскә төренгәннәр.
Күреп булмый аякларын,
Ак карга кумелгәннәр.

Куркып салкын җиллnetwork
Кар бияләй кигәннәр.
Башларына бүрекләр дә
Киеп куйган имәннәр.

Сылу каен кызлары да
Ак шәлләрен япканнар.
Ә юкәләр, егетләнеп,
Кар галстук такканнар.



Әниемне котладым



Сигезенче Мартта әниемне
Зур бәйрәме белән котладым.
Аңа бәхет, сәламәтлек теләп,
Матур итеп җырлар җырладым.

Әниемне шатландырыр өчен,
Бүлмәләрне чистартып куйдым.
Үзем үстергән чәчәкне тотып
Аны эшеннән каршы алдым.

Әни мине кочагына алды,
Мактап, назлап аркамнан сөйде.
Булдыргансың, кызым, рәхмәт сиңа,
Бәхет-тәүфыйк белән үс, диде.

Кояш белән дуслаштым



Кояш белән исәнләштем,
Мәңгелеккә дуслаштым.
Нурлы елмаюын күреп
Чын күңелдән сокландым.

Кушымта:
Кояш, беркайчан сүрелмә,
Җиһанны яктыртып тор.
Җирдәге бар тереклеккә
Нурың сибеп балкып тор.

Кояш сөеп, назлап кына
Карый миңа һәр иртә.
Мөлаем карашы белән
Мине бәхетле итә.
Кушымта.

Әйтерсең, гел минем өчен
Җылы нурларын сибә.
Кояштан көч, кодрәт алып,
Минем йөрәгем тибә.
Кушымта.

Әбигә бүләк



Гаиләдә баш ватабыз,
Ни бүләк итәргә дип.
Чөнки бүген дәү әбинең
Сиксән яше тулган бит.

Әй уйлыйбыз, серләшәбез,
Нинди бүләк бирергә.
Берәр гаҗәп әйбер алып,
Ничек сөендерергә.

Әлфия дәшми торды да,
Мин уйлап таптым, диде.
Әбигә иң кирәк бүләк,
Намазлык, дисбе инде.

Шулай итеп бик шәп бүләк,
Дисбе, намазлык алдык.
Сиксән яше тулган көнне,
Әбине шатландырдык.

Карт песи



Син дә картайдың, песием,
Гел хәрәкәт итмисең.
Йомарланып ятасың да
Бер нәрсә дә сизмисең.

Яшь чакларыңдагы кебек
Алдыма да менмисең.
Уймакларны тәгәрәтеп
Инде уйный белмисең.

Ашауыңның да рәте юк,
Иркәләүне оймыйсың.
Яныңда күселәр йөри,
Син аларны кумыйсың.

Әй, песием, песикәем,
Син дә картайдың бугай.
Әйдә уян, дәртләрәк бул,
Безгә күңелсез болай.

Тамчылар





Өйләрнең түбәләреннән
Тук-тук тама тамчылар.
Үзләренә юллар ерып
Елгаларга агалар.
Кушымта:
Ләйсән яңгыр яуган чакта
Табигать матурлана.
Шиңгән гөлләр дә яшәрә,
Көч ала һәм җанлана.

Балалар яңгыр суында
Уйнарга яраталар.
Лычтыр-лычтыр йөгерәләр,
Көймәләр агызалар.
Кушымта.

Ләйсән яңгыр яу, дип, алар,
Матур җырлар җырлыйлар.
Түбәдән аккан тамчының
Моңлы көен тыңлыйлар.
Кушымта.

Сандугач, сыерчык



Сандугач белән сыерчык
Минем якын дусларым.
Икесе дә матур сайрый,
Өзелеп сөям җырларын.

Кушымта:
Канатларыгызны кагып,
Сайрыйсыз сез, кошларым.
Сез минем күңлем кояшы,
Алмаштырмас дусларым.



Көн дә таңнан торып сайрап
Моңлы көйләр тезәсез.
Йөрәкләргә үтеп кереп
Үзәкләрне өзәсез.
Кушымта.

Сандугач та, сыерчык та,
Гел матур җыр җырлыйлар.
Бар дөньяга моң таратып,
Тыңлаучыны зурлыйлар.
Кушымта.

Туган телем

Әнвәр Шәрипов сүзләре.





Әнкәм сөте белән йөрәгемә,
Тән-җаныма үтеп кердең син,
Гомер буе күңелемне назлап,
Тугры юлдаш булып йөрдең син.

Кушымта:
И мөкатдәс әткәм-әнкәм теле!
Изге телем, газиз телем син!
Югалмассың, туган халкымны син
Ерак гасырларга илтерсең.

Иң беренче "Әти-әни" сүзен
Туган телемдә мин әйткәнмен.
Әлифбадан тәүге "Әни" сүзен
Укып, сөенеп өйгә кайтканмын.

Кушымта:
Туган телдә "сөям" сүзе белән
Чәчәк атты яшьлек хисләрем.
Шушы телдә тәмләп мин сөйләшәм
Көндезләрен, иртә, кичләрен.

Гомер үтәр, соңгы сүземне дә
Әйтермен мин туган телемдә.
Оныклар да чиста, матур итеп,
Сөйләшерләр ана телендә.

Кушымта:
И мөкатдәс әткәм-әнкәм теле!
Изге телем, газиз телем син!
Югалмассың, туган халкымны син
Ерак гасырларга илтерсең.

Көмеш кыңгырау

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

"Көмеш кыңгырау"ны гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы.

"Көмеш кыңгырау" газетасы массакүләм мәгълүмат чаралары һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендәге законнарны үтәүгә күзәтчелек итүче федераль хезмәтенең Идель буе идарәсендә ПИ №ФС7-3729 саны белән теркәлде.
Адрес: 423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Гидротөзүчеләр урамы, 10нчы йорт, 429нчы бүлмә. "Көмеш кыңгырау" газетасы редакциясе.
E-mail:komesh_k@List.ru

Җаваплылыгы чикләнгән "Глагол" ширкәте типографиясендә басылды. Язмаларның эчтәлеге һәм аларны газетада урнаштыруның сыйфаты өчен типография җавап бирми.

Басарга кул куелды
10.11.2006

Индекс - 31700
Тираж - 3057